
# ***Язучы Зифа Кадырова белән очрашу кичәсе***

**79 нчы Экология-технология лицее 22 ноябрь 16:00 сәгатьтә**



## ***“Бәхеткә юл кайдан...”***



- Татар әдәбиятын, татар китабын сөючеләр өчен 2024 елның 22 ноябрь көнендә 79 лицей китапханәсендә Яр Чаллы шәһәреннән килгән бик зур кунак – популяр язучы Зифа Кадырова һәм аның иҗатташ дуслары – “Ләйсән” әдәби иҗат берләшмәсе җитәкчесе Хәмидуллина Роза Галимулла кызы, өметле шагыйрь Шәйхетдинов Айрат Әсләхетдин улы белән очрашу оештырылды! Әлеге очрашу мәктәп тормышын төрле кызыклы чаралар белән баетырга омтылучы лицей директоры Гөлназ Ринатовна Галеева тәкъдиме белән үткәрелде.

- Зифа Кадыйрова исеме бүген китап яратучы һәркемгә яхшы таныш. «Синсез килгән язлар», «Сагынырсың, мин булмам», «Көтеп узган гомер», «Язмыш сынавы» «Урланган яшьлек», «Бәхеткә юл кайдан» китапларының ***үз укучысын булдыруының сере үз эченә яралы язмышларны сыйдыруы*** белән бәйле.

- Бүгенге очрашуда Зифа Кадырова үзенең әнә шул геройлары – гыйбрәтле язмышларга ия хатын-кызлар, аналар, аларның прототиплары хакында сөйләде.

- Матди байлык, алыш-биреш өстенлек иткән бу көннәрдә мәхәббәткә урын бармы дигән сорауга җавап эзләде кунаклар.

- Әдәбият дөньясына язгы ташкын кебек килеп кергән, һәркемгә таныш хис-тойгыларны гади тел белән үзәкләрне өзәрлек итеп тасвирлап, күңелләрне әсир иткән Зифа ханым белән очрашу үтә җылы, дустанә мохиттә узды һәм күңелләрдә матур тәэсир калдырды. Менә шундый бай рухлы, көчле ихтыярлы язучы булып чыкты Зифа Кадырова!

- Иҗатташ дуслары да Зифа Кадырова китапларының күпләр өчен рухи кыйбла, тормышта аяныч хәлләргә юлыгучыларга ныклы таяныч булуын сөйләделәр. Үзләренең иҗат җимешләре белән дә бүлештеләр – Айрат Шәйхетдинов гомумкешелек кыйммәтләре турында “Чыж-чыж.., шарт-шорт...” фәлсәфи шигырен укыганда кунакларның күзендә яшь иде!

- Һәр очрашуның рухи яктан баетуын аңлап, киләчәктә исән-сау күрешергә насыйп булсын дип таралды Чаллы кунаклары!


УРЛАНГАН ЯШЬЛЕК



ВЫХОД











